**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНДЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**дүртенче чакырылыш егерме өченче утырыш**

**«10» апрель 2023 ел № 75 Баландыш ав.**

Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге җирле үзидарәсенең концессион килешү төзү турында тәкъдимне карау буенча вәкаләтле органы турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясының 4.4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының 2023 елның 13 мартындагы 01/613 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең концессион килешү төзү турында тәкъдимне карау буенча вәкаләтле органы итеп Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Баландыш авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Мөхәммәтшин